

Бәйрәм горләп барган вакытта «Фестивальная» мәйданчыгында кем жырчыга кушылып жырлый, кем дәртле жырга кушылып бии...
Ләмберә районы Аксёново авылында vткән Ботенроссия авыл Сабан туенда, башкалар белән беррәттән, Вил Усманов - профессиональ татар жырчысы, композитор, Татарстаннын халык артисты чыгышын тынладым.      Матур кое белән халыкнын кvнелен тибрәндерде Вил Нургали улы. Берничә жырын рәхәтләнеп тынлагач, сцена янына тошкән артист белән әнгәмә кордым. Олы жанлы жырчы сорауларыма тулы жавап бирде.
Сабантуйдан алган хис-кичерешлә-регез белән уртаклашыр идегез дип сорагач, ул: «Аксёновода vтә торган XII Ботенроссия авыл Сабантуе - Россия халыкларынын мәдәни мирасы елынын ин моһим вакыйгаларынын берсе дип әйтергә урын бар. Дуслыкны берләштерә торган бәйрәм бу. Торле милләт халкынын мәдәнияты тәгъдим ителгән. Һәрбер почмакта туган татар телебез янгырый: бердәм булыйк, бергә булыйк.
Тулаем бәйрәмгә килгәндә - тырышып әзерләнелгән чара, һәрбер әйбер уйланылган: мәйданнары, парковкаларына кадәр... Мин катнашкан концертта мордва артистлары номерлары Татарстанныкылар белән бергә vрелеп бара.»
Зур рәхмәтләр әйтеп, матур теләкләр теләп хушлаштым Вил Усманов белән.

**Наилә НАСЫРОВА**